# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## “Оешмалар мөлкәтенә салым турында” Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 26 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Оешмалар мөлкәтенә салым турында” 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы $1^1$ өлешен (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

“$1^1$. 0,01 процент күләмендәге салым ставкасы 2011 елның 1 гыйнварыннан 2014 елның 1 гыйнварына кадәр эксплуатациягә кертелгән, техник документация буенча машина урыннары саны кимендә 100 берәмлек булган автомототранспорт чараларын куеп торуның күпкатлы һәм җир асты урыннарында (парковкаларда) автомототранспорт чараларын куеп тору урыннары (парковкалар) хезмәтләре күрсәтү өчен билгеләнгән мөлкәткә автомототранспорт чараларын куеп тору урыннары (парковкалар) хезмәтләре күрсәтү өчен, әлеге куеп тору урыннарының (парковкаларның) гомуми мәйданының кимендә 70 процентын файдалану шарты белән билгеләнә.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2013 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 26 декабре
№ 103-ТРЗ

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ